СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**Сеҗе авыл җирлеге карары**

**« 19 » декабрь 2022 ел** **№ 76**

**Җирле салымнар недоимкасын, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә җирле салымнар буенча недоимканы, бу салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында Сеҗе авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Җирле салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен (алга таба - бурыч) билгеләргә:

- бурыч барлыкка килү датасы өч елдан артык булган үлгән яисә аларны Россия Федерациясенең Граждан процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителгән физик затларның җир салымы һәм мөлкәти салымы буенча;

- үлгән яки үлгән дип танылган физик затларның мирасны ачкан көннән бер ел эчендә варислары мирас хокукыннан баш тарткан очракта, варислары булмаган яки мирасны алмаган очракта, җир салымы һәм мөлкәти салым буенча;

- 2006 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар булган очракта, җир салымы буенча;

- бурычлы кешенең түләтелергә тиешле мөлкәте булмага очракта, бурычлары 3 елдан артык вакытта барлыкка килгән Россия Федерациясеннән читкә киткән физик затларның җир салымы һәм мөлкәти салымы буенча;

- картлар (ветераннар) йортларында яшәүче физик затларның җир салымы һәм мөлкәти салымы буенча;

- суд карары нигезендә һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булган чорда иректән мәхрүм итү урыннарындагы физик затларның җир салымы һәм мөлкәти салымы буенча.

2. “Җирле салымнар недоимкасын, бу салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында” Сеҗе авыл җирлеге Советының 11.10.2019 ел, № 106 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р.В.Хәмидуллин